СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш. Маннура, д.72 а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ш. Маннур ур., 72 а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР**
№ 2-36

**РЕШЕНИЕ**
24 сентябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында" 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Олыяз авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 17-нче сентябрендә кабул ителгән 33 номерлы карары, Олыяз авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 17-нче сентябрендә кабул ителгән 6-35 номерлы карары, Олыяз авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Олыяз авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре” 2014 нче елның 2-нче апрелендә кабул ителгән 2-33 номерлы (17 сентябрь 2018 ел №5-35 редакциясендә) карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2018 нче елның 18 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара

салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:**

-Түбән Козгынчы торак пунктында Татарстан, Октябрь, К.Маркс,Югары Козгынчы торак пунктында Тракторист, Тәмле Чишмә, Олыяз торак пунктында Тукай, Яңа, С.Габдрауф урамнары ягына баручы юлларга вакташ җәеп ремонтлау;

-Кыравыл авылында юлга ясалма тигезсезлек урнаштыру.

- Авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

2. **Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру:**

Тулбай, Түбән Козгынчы авылларында чишмәне ремонтлау һәм төзекләндерү.

Дусай авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның һәйкәлен ремонтлау

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы И.Я.Хаевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /И.Я.Хаев/